Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

Олы Әшнәк авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 1

2026 елның 20нче январе

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»2023 елның 02 маендагы IX-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Олы Әшнәк» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 №425-ФЗ Федераль закон нигезендә Совет Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Әшнәк авыл җирлеген карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 02 маендагы IX-1 номерлы карарына (18.06.2024 №III-1, 29.10.2024 №XI-1 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

.1. 1 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик затның Россия Федерациясе Граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә вафат булуы турында игълан ителүе (мондый физик затка карата банкротлык турында эш кузгатылган очрактан тыш):

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелмәгән салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча бурычлар өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артыграк күләмдә, шул исәптән мирас Россия Федерациясе милкенә күчкән очракта да, бурыч өлешендә;

Россия Федерациясе Салым Кодексының 14 статьясындагы 3 пунктында һәм 15 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән салымнар буенча аның мирас мөлкәте хакыннан артмаган күләмдә бурыч өлешендә мондый физик зат вафат булганнан соң өч ел узгач һәм салым органында мондый мөлкәтне мирас итеп алу факты турында мәгълүмат булмаганда;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Балык Бистәсе муниципаль
районы Олы Әшнәк
авыл җирлеге Башлыгы Р.Ә. Хөснетдинова